**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 13.08.2018 № 1767

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә ата-аналардан балаларны карау-тәрбияләү өчен түләү алу Биектау муниципаль районында социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы” 2018 ел, 30 нчы март 717 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт социаль ярдәме турында” 1999 ел, 17 нче июль, 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Адреслылык принцибын саклау һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль яклау чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 ел, 29 декабрь, 388-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында” 2017 ел, 14 февраль, 181 нче номерлы карары, Татартсан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нормаларын тормышка ашыру максатыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә ата-аналардан балаларны карау-тәрбияләү өчен түләү алу Биектау муниципаль районында социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы” 2018 ел, 30 нчы март 717 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1, 2.2 пунктларны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“2.1. Карар нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар, күрсәтелгән социаль ярдәм турында мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан

билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә бирүне тәэмин итәргә.

2.2 Түбәндәге карар нигезендә социаль ярдәм алучы аерым категория гражданнар турында мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә алырга мөмкин.”.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә әлеге карарның күчермәсен Россия Федерациясе Пенсия фонды Идарәсенең Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районындагы бүлегенә җибәрергә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайты аша халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Сабирҗанов Р.Р.га йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ИНН 1616014806 ОГРН 1061683000280